**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты**

# Карар

2022ел 24 октябрь №23

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә 16 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында «Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 340-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендә 16 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктында:

1) дүртенче абзацта «күрсәтүнең» сүзен гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны кисәтүдә һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрендә катнашу, шулай ук күрсәтүнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

«гражданнарның хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашуы.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Ф.Х.Гарифуллина